ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№1427 от «13» 11 2017 г.

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2013 елның 18 сентябрендәге
«Мәктәпкәчә белем бирү программасын
гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына
йөрүче балалары булган гражданнарга
социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»
1333 номерлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслы булу принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып, социаль ярдәм чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге №388 – ФЗ Федераль закон, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендә кабул ителгән № 178- «ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 18 сентябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»1333 номерлы карарына (14.02.2014 № 150, 12.07.2016 № 819, 06.03.2017 № 237 )түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенең 2.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге карар нигезендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга документлар кабул итүне һәм компенсация түләүләрен билгеләүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) файдалану юлы белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән формат нигезендә мәгълүмат тапшыруны тәэмин итә.

Документларны кабул итү һәм мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре турындагы мәгълүмат ЕГИССОдан Россия Федерациясе

Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматта файдалану юлы белән алынырга мөмкин.".
Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.Э.Фәттәхов